**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

14 нче сентябрь 2016 ел №70

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2015 елның 2 ноябрендәге 9 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләр туктатылган очракта, 35 статьясындагы 16 өлешенең җиденче абзацында, 6 өлешнең 2.1, 3, 6 - 9 пунктларында, 36 статьясындагы 6.1 өлешендә, 7.1 өлешендә, 10 өлешенең 5 - 8 пунктларында, 40 статьясындагы 10.1 өлешендә, 73 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә каралган буенча түләнми.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге**
**башлыгы урынбасары, Совет рәисе** **Р.С. Кадиров**